ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ
ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ МӘГАРИФ ОЕШМАСЫ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕН) ҺӘМ ӘДӘБИЯТНЫ УКЫТУДА

ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕКНЕҢ РОЛЕ


ТАТАССР
Празднование 100-летия
Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең
100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020


ПОБЕДА!
1945–2020

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ
АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕН) ҺӘМ ӘДӘБИЯТНЫ УКЫТУДА ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕКНЕҢ РОЛЕ

Методик тәкъдимнәр

Казан
2019

ББК 74.268
Т 81

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы белән килешенеп,
ТРМҮИ Гыйльми советы карары нигезендә басыла

Ногманова Л.Н., ТРМҮИ ректоры, педагогика фәннәре докторы

Фәнни мөхәррир: Шәмсетдинова Р.Р., ТРМҮИ татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, доцент, филология фәннәре кандидаты

Рецензент: Җамалетдинова З.И., ТРМҮИ мәктәпкәчә һәм башлангыч гомуми белем бирү кафедрасы доценты, педагогика фәннәре кандидаты

Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р.Р., ТРМҮИ татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, доцент, филология фәннәре кандидаты; Фәттахова Р.Ф., татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты; Гыйләҗева Л.Г., татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты; Хадиева Г.В., татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы

Туган тел (татар телен) һәм әдәбиятны укытуда дәрестән тыш эшчәнлекнең роле / төз.: Шәмсетдинова Р.Р., Фәттахова Р.Ф., Гыйләҗева Л.Г., Хадиева Г.В.. — Казан: ТРМҮИ, 2019. — 40 б.

Хезмәт белем бирү оешмаларында эшләүче туган тел (татар теле) һәм әдәбият укытучыларына, мәктәп җитәкчеләренә, милли мәгариф хезмәткәрләренә тәкъдим ителә. Методик ярдәмлектә федераль дәүләт стандартлары шартларында белем бирү оешмаларында дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру буенча методик тәкъдимнәр бирелә: дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру үзенчәлекләре яктыртыла, дәрестән тыш эшчәнлек аша туган тел һәм дәүләт теле буларак татар телен һәм әдәбиятны укытуны камилләштерү мөмкинлекләре күрсәтелә, кушымтада дәрестән тыш эшчәнлек төрләре буларак проект эшләре темалары, чара үрнәкләре урын алган.

© ТРМҮИ, 2019

ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНДА ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕКНЕ ОЕШТЫРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Федераль дәүләт стандартлары шартларында белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программасы дәрестә укыту эшчәнлеге һәм дәрестән тыш эшчәнлек аша дәүләт санитар-эпидимиологик кагыйдәләрне һәм нормативларны үтәп тормышка ашырыла (СанПиН 2.4.2.2821-10, 2015 елның 24 ноябрь редакциясендә). Дәрестән тыш эшчәнлек — дәрестә уку эшчәнлегеннән кала укучыларга белем бирү һәм аларны тәрбияләү максатына юнәлдерелгән барлык эш төрләре.

Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләре буенча, мәктәптә алып барылган дәрестән тыш эшчәнлек дәресләрдә алган белемнәрне ныгытуга, тирәнәйтүгә, киңәйтүгә хезмәт итәргә, белем бирү процессында шәхескә караган һәм метапредмет (универсаль) уку гамәлләрен формалаштырырга тиеш. Төп максат — укучыларның кызыксынуларын, сәләтләрен һәм ихтыяҗларын канәгатьләндерерлек шартлар тудыру һәм аларның буш вакытларын дөрес оештыру, шуның нигезендә тәрбияләү һәм социальләштерү максатына ирешү.

Төп гомуми белем бирүнең ФДББС шартларында дәрестән тыш эшчәнлек түбәндәге норматив документлар һәм материалларга нигезләнеп оештырыла:

– Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының «Гомуми белем бирү федераль дәүләт белем бирү стандартларын керткәндә дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру турында» хаты, 12 май 2011 ел, №03-296;

– СанПиН 2.4.2.2821-10 «Гомуми белем бирү оешмаларында укыту шартларына һәм укытуны оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр»;

– СанПиН 2.4.4.1251-03 «Балаларга өстәмә белем бирү оешмаларына санитар-эпидемиологик таләпләр»;

– Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының «Гомуми белем бирү оешмаларында тәрбия бирү компонентын үстерү Программасының юнәлеше турында» хаты, 13 май 2013 ел, № ИР-352/09;

– Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының «Гомуми белем бирү оешмаларында тәрбия бирү компонентын үстерү Программасын тормышка ашыруда чаралар исемлеген формалаштыру буенча тәкъдимнәр турында» хаты, 12 июль 2013 ел, № 09-879;

– Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының «Дәрестән тыш эшчәнлек һәм өстәмә гомуми белем бирү программасын тормышка ашыру турында» хаты, 14 декабрь 2015 ел, № 09-3564.

Федераль дәүләт белем бирү стандартлары тарафыннан мәктәптә дәрестән тыш эшчәнлекне оештыруга түбәндәге таләпләр куела:

– дәрестән тыш эшчәнлек мәктәптә төп белем бирү программасының аерылгысыз өлеше буларак мәктәпнең төп белем бирү программасы составына кертелә;

– мәктәптә дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру мәҗбүри;

– дәрестән тыш эшчәнлек ФДББС таләпләрен тулысынча тормышка ашыруга ярдәм итә;

– программаның әлеге өлешенә караган эчтәлекне тутыру, максат-бурычларны күрсәтү белем бирү учреждениесенең үз компетенциясендә;

– төп белем бирү стандартларын тормышка ашыру юлында белем бирү процессын оештыру юнәлешләрен һәм формаларын сайлауны, дәрес һәм дәрестән тыш эшчәнлекне чиратлаштыруны белем бирү оешмасы үзе билгели;

– дәрестән тыш эшләр өчен сәгатьләр билгеләү укучылар һәм ата-аналар теләгеннән (мөмкинлегеннән) чыгып эшләнелә.

Дәрестән тыш эшчәнлекнең төп юнәлешләре:

– гомуми интеллектуаль;
– гомуми мәдәни;
– рухи-әхлакый;
– спорт-сәламәтлекне саклау;
– нәфис-эстетик;
– хәрби-патриотик;
– иҗтимагый-файдалы эшчәнлек.

Эш төрләре:

– уен;
– танып белү;
– рухи кыйммәткә юнәлдерелгән проблемалы аралашу;
– сәнгати иҗат;
– техник иҗат;
– хезмәт;
– спорт-сәламәтләндерү эшчәнлеге;
– туризм, төбәкне өйрәнү эшчәнлеге һ.б.

Эш формалары:

– түгәрәкләр (әдәби, татар телен һәм әдәбитын тирәнтен өйрәнү);
– экскурсияләр (музейларга, тарихи урыннарга);
– нәфис студияләр;
– спорт клублары һәм секцияләре;
– яшүсмерләр оешмалары;
– төбәкне өйрәнү эше;
– мәктәп укучыларының фәнни оешмалары;

– фәнни-гамәли конференцияләр;
– олимпиадалар;
– ярышлар, диспутлар, бәйгеләр (җыр, сәнгатьле уку, иншалар, шигырьләр язу);
– эзләнү, фәнни тикшеренүләр;
– иҗтимагый файдалы гамәлләр;
– хәрби-патриотик оешмалар һ.б.

Төп гомуми белем бирүнең ФДББС һәр гомуми белем бирү баскычында дәрестән тыш эшчәнлеккә тиешле гомуми сәгатьләр санын төгәл куя: башлангыч белем бирү баскычында — 1350 сәгатькә кадәр, төп гомуми белем бирү баскычында — 1750 сәгатькә кадәр, урта гомуми белем бирү баскычында — 700 сәгатькә кадәр. Мәктәп, үзенең төп белем бирү программасының эчтәлеге һәм оештыру үзенчәлегеннән чыгып, дәрестән тыш эшләргә сәгатьләр санын үзе билгели ала. Ләкин СанПиН 2.4.2.2821-10 укучыларның максималь атналык белем алу күләменә гигиеник таләпләрне төгәл куя (п. 10.5): мәсәлән, 5-9 сыйныфларда, уку атнасының озынлыгы күпме булуга карамастан, атналык дәрестән тыш эшләр күләме 10 сәгатьтән артмаска тиеш. Дәрестән тыш шөгыль 35-45 минут дәвам итәргә мөмкин. Шулай ук дәрестән тыш эшчәнлек сәгатьләренең уку атнасында да, бәйрәм һәм ял көннәрендә дә, каникул вакытында да иҗтимагый файдалы эшләр башкару, тикшеренү эшчәнлеген алып бару, экскурсияләр, походлар, ярышлар үткәрү, театрларга, музейларга бару һәм башка чаралар өчен куллану мөмкинлеге ассызыклана. Дөрес оештырылган дәрестән тыш эшчәнлек системасы туган тел (татар теле) һәм әдәбиятны туган тел һәм дәүләт теле буларак укытуны ныгытырга, укучыларның үсеше өчен өстәмә шартлар тудырырга тиеш.

ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕКНЕ ОЕШТЫРУДА ТӨП ПРИНЦИПЛАР ҺӘМ МОДЕЛЬЛӘР

Дәрестән тыш эшчәнлек педагогка балаларның потенциаль мөмкинлекләрен һәм кызыксынуларын белергә ярдәм итә. Дәрестән тыш эшчәнлек — укучылар коллективын һәм укучыларның үзидарә органнарын булдыру максаты белән укучылар һәм сыйныф җитәкчесе арасында шәхесара мөнәсәбәтләр урнаштыру өчен бик әйбәт мөмкинлек ул.

Төрле яклы дәрестән тыш эшчәнлек процессы укучыларның гомуммәдәни мәнфәгатьләренең үсешен тәэмин итәргә, әхлак тәрбия бирү бурычларын хәл итәргә булышырга мөмкин.

Дәрестән тыш эшчәнлек балаларга өстәмә белем бирү белән бәйләнгән, бу вакытта балаларның сәләтләрен үстерү өчен шартлар булдыру һәм аларны сәнгать, техник, экологик-биологик, спорт һәм башка эшчәнлеккә тарту эше турында сүз бара.

Факультативлар, мәктәпнең фәнни оешмалары эшчәнлеге, сайлап алу буенча уку курслары дәрестән тыш эшчәнлек белән балаларның өстәмә белем алулары арасында бәйләп торучы чылбыр булып тора.

Дәрестән тыш эшчәнлекне гомуми принциплар рәте нигезендә төзү үзен аклый.

Гуманлаштыру принцибы укучыларны кыйммәтләр системасында дөрес ориентлаша белергә һәм төрле мәдәниятләр диалогына керергә ярдәм итә.

Эчке һәм тышкы дифференциация принцибы — укучыларның иҗади эшчәнлекнең төрле юнәлешләрендә эшләү мөмкинлекләрен һәм сәләтләрен билгеләү һәм үстерү, үзенә якын булган дисциплиналар сайлау мөмкинлеген һәм аларга һәрбер конкрет предметны үзләштерүнең төрле тирәнлегендә эшләп карау мөмкинлеген булдыру ул.

Сайлау иреге принцибы — укучыларның үзләренә дәрестән тыш эшчәнлекнең формаларын һәм төрләрен мөстәкыйль рәвештә сайлап алу мөмкинлеген тәкъдим итү, үзенең нәтиҗәләре өчен җаваплылык хисе тәрбияләү.

Ирекле үзбилгеләнү һәм *үз-үзеңне тормышка әзерләү* мөмкинлеге.

Баланың шәхси мәнфәгатьләренә, ихтыяҗларына, сәләтенә йөз тоту.

Бердәмлек принцибы — укыту, тәрбия бирү, үсеш бердәмлеге.

БЕЛЕМ БИРҮ ПРОЦЕССЫНЫҢ ГАМӘЛИ-ӘШЧӘНЛЕКЛЕ НИГЕЗЕ. ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕК НӘТИҖӘЛӘРЕ

Укучыларның дәрестән тыш эшчәнлекнең тәрбияви нәтиҗәләре өч дәрәҗәдә билгеләнә.

Нәтиҗәләрнең беренче дәрәҗәсе — укучыларның социаль белем алулары (иҗтимагый нормалар, җәмгыятьнең төзелеше, җәмгыятьтә социаль яктан кабул ителә һәм кабул ителми торган үз-үзеңне тоту формалары һ.б.), социаль чынбарлыкны һәм көндәлек тормышны аңлау.

Нәтиҗәләрнең әлеге дәрәҗәсенә ирешү өчен укучының (аның өчен мөһим булган) уңай социаль белем һәм көндәлек тәҗрибә чыганагы булган шәхесләр — укытучылары белән үзара бәйләнеше зур әһәмияткә ия (нигездә, өстәмә белем бирүдә).

Нәтиҗәләрнең икенче дәрәҗәсе — укучының җәмгыятьнең база кыйммәтләренә карата булган борчылуларын һәм позитив мөнәсәбәтләрен (кеше, гаилә, Ватан, табигать, дөнья, белем, хезмәт, мәдәният) алуы.

Нәтиҗәләрнең әлеге дәрәҗәсенә ирешү өчен укучыларның сыйныф, мәктәп дәрәҗәсендә, ягъни дустанә просоциаль тирәлектә аралашулары зур әһәмияткә ия. Нәкъ менә шундый социаль тирәлектә бала үзендә булдырылган социаль белемнәрен практик яктан раслый, аларның кадерен белә башлый.

Нәтиҗәләрнең өченче дәрәҗәсе — укучының мөстәкыйль рәвештә башкарган иҗтимагый гамәлләр тәҗрибәсен алуы. Бары тик мөстәкыйль рәвештә башкарган иҗтимагый гамәлләр вакытында гына, ачык социумдагы эшчәнлегендә, мәктәпнең дустанә тирәлегеннән читтә генә яшь кеше, чынлыкта, социаль хезмәткәр, гражданин, ирекле кеше була ала. Нәкъ менә шундый мөстәкыйль рәвештә башкарган иҗтимагый гамәлләр нигезендә генә алардан башка гражданинның һәм гражданлык җәмгыятенең яшәешен күз алдына китереп булмаган батырлык, лаеклы эш-гамәлләргә әзер булу кебек тормышта бик кирәкле тәҗрибә алып була.

Дәрестән тыш эшчәнлек нәтиҗәләренең өч дәрәҗәсенә дә ирешү балаларда тәрбия һәм социальләшү эффектлары барлыкка килү мөмкинлеген арттыра.

Кече яшьтәге мәктәп укучыларының дәрестән тыш эшчәнлеген оештырганда, 1 нче сыйныфка кергән балалар яңа социаль белемгә тартылучан, үзләре өчен яңа булган мәктәп чынбарлыгын аңларга омтылучан булуларын исәпкә алырга кирәк. Педагог бу тенденцияне хупларга, дәрестән тыш эшчәнлекнең кулланыла торган формалары ярдәмендә баланың *беренче дәрәҗә нәтиҗәләренә* ирешүен тәэмин итәргә тиеш.

2, 3, 4, 5нче сыйныфларда, кагыйдә буларак, балалар коллективының үсеше процессы көч ала, кече яшьтәге мәктәп укучыларының шәхесара мөнәсәбәтләре кискен активлаша, бу исә дәрестән тыш эшчәнлек нәтиҗәләрнең икенче дәрәҗәсенә ирешү өчен бик уңышлы ситуация тудыра.

Мәктәптә дүрт ел уку дәвамында беренче дәрәҗә нәтиҗәләреннән эзлекле рәвештә икенче дәрәҗә нәтиҗәләренә күчү кече яшьтәге мәктәп укучыларының 5–6нчы сыйныфта исә иҗтимагый эш, гамәлләр киңлегенә чыгу мөмкинлеген арттыра (ягъни нәтиҗәләрнең өченче дәрәҗәсенә ирешү). Мондый күчеш башлангыч һәм 5 нче сыйныф укучысы өчен дустанә тирәлеккә чыгу буларак билгеләнергә тиеш. Хәзерге заман социаль ситуациясенә хас булган конфликтлылык һәм билгесезлекнең билгеле бер дәрәҗәдә чикле булуы мөһим.

Дәрестән тыш эшчәнлек укучыларның шәхси ихтыяҗларын тәэмин итә.

Дәресләрдән соңгы мәктәп — бала өчен иҗат дөньясы, аның кызыксынуларын, мавыгуларын, үз-үзен ачуы ул. Биредә бала сайлау хокукына ия, үз ихтыярын эшкә җигә ала, шәхес буларак ачыла. Мәктәп аның өчен икенче өе булып, дәрестән тыш эшчәнлекне тәрбия һәм белем бирүнең тулы бер пространствосына әйләндерү өчен баланы дәресләрдән соң төрле шөгыльләр белән кызыксындыру мөһим. Дәресләрдән тыш эшчәнлек вакытында мавыгучан балалар белән педагогның үзенчәлекле эмоциональ тирәлеге хасил була, биредә спорт, сәнгать, фән, техника һәм башка төр эшчәнлектә уңышка омтылган укучыларның белем алулары тормышка ашырыла.

Федераль дәүләт белем бирү стандартларында күрсәтелгәнчә, дәрестән тыш эшчәнлек белем бирү һәм тәрбия процессының аерылгысыз бер өлеше һәм укучыларның буш вакытларын оештыруның бер формасы булып тора. Бүгенге көндә дәрестән соң эшчәнлек дәрестән соңгы вакытта укучыларның ихтыяҗларын канәгатьләндереп оештырыла торган эшчәнлек итеп күзаллана.

Дөрес оештырылган дәрестән тыш эшчәнлек системасы укучының конкурентлылыкка сәләтлелегендә чагылачак өлкә булып тора. Мәктәп һәм өстәмә белем бирү оешмалары белем бирүнең вариативлылыгын, сайлау мөмкинлеген тәэмин итәләр.

– дәрестән тыш эшчәнлек — төп белем бирүнең яңа төр уку эшчәнлеген үзләштерүдә педагогка һәм укучыга ярдәм итүгә юнәлгән, уку мотивациясен үзгәртүгә сәләтле өлеше;

– ул белем бирү пространствосын киңәйтергә ярдәм итә, укучыларның үсеше өчен өстәмә шартлар тудыра;

– дәрестән тыш эшчәнлек белем бирүнең бөтен периодларында җайлашу, ияләшү этапларында балаларга ярдәм итүне тәэмин итә торган эшчәнлек булырга тиеш.

Ә бу исә билгеләнгән белем бирү нәтиҗәсенә чыгу — база белемнәрен уку процессыннан тыш башка ситуацияләрдә кулланырга әзер булу. Гомумән, бу исә төрле балалар өчен уңыш ситуациясе дә, социальләшүне тәэмин итү дә булып тора.

Дәрестән тыш эшчәнлек — шәхескә караган һәм метапредмет нәтиҗәләре ул. Бу исә әлеге процесста дәрестән тыш эшчәнлекнең үзенчәлеген дә билгели.

Дәрестән тыш эшчәнлекне оештыруның моделен түбәндәге алгоритм буенча гамәлгә ашырырга мөмкин:

I этап — дәрестән тыш эшчәнлекнең максатларын, принципларын, аларның төп белем бирү программаларында чагылыш табуларын билгеләү;

II этап — белем бирү оешмалары тарафыннан дәрестән тыш эшчәнлекнең тәкъдим ителгән модельләренә анализ ясау;

III этап — дәрестән тыш эшчәнлекнең төрле модельләрен ресурслары ягыннан тәэмин ителешенә анализ ясау;

IV этап — дәрестән тыш эшчәнлекне оештыруның моделен сайлау, максатлар, принциплары, аның тормышка ашырылу мөмкинлекләре белән ярашлы хәлдә аның эчтәлек ягыннан тулыландырылуы, тавсвирламасы.

Дәрестән тыш эшчәнлекне алгоритм нигезендә оештыру Федераль дәүләт белем бирү стандартларында гамәлгә кертүне тәэмин итүдә уңышлы юл булып тора.

Белем бирү учреждениеләренең дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру модельләренең берничә классификациясе бар.

Мәктәп эчендәге модель учреждениенең дәрестән тыш эшчәнлекне үткәрергә тиешле ресурслар комплексы булганда тормышка ашырыла.

Тышкы модель учреждениенең дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру өчен үз ресурслары булмаганда тормышка ашырыла. Дәрестән тыш эшчәнлек программасын тормышка ашыру бер яки берничә учреждение — социаль партнёрлар арасында булырга мөмкин.

Катнаш модель иң еш кулланыла торган модель, бер яктан, күп кенә оешмалар дәрестән тыш эшчәнлекне оештыруда ресурсларга кытлык кичерәләр, икенче яктан, өстәмә белем бирү оешмалары белән булган мөнәсәбәтләрне сакларга һәм үстерергә тырышалар.

Өстәмә белем бирү моделе (өстәмә белем бирүнең институциональ нигезендә) факультативлар, мәктәпнең фәнни оешмалары, һөнәри юнәлгән оешмалар, сайлап алу буенча курслар кебек формалар бәйләп торучы чылбыр булып торалар. Эшчәнлеккә өстәмә белем бирү белгечләрен тарту, шулай ук белем бирү процессын практик-юнәлгәнлек һәм эшчәнлекле нигездә оештыру әлеге модельнең өстенлеге булып тора.

«Тулы көн мәктәбе» моделе. «Тулы көн мәктәбе» моделенең нигезе булып дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру озайтылган көн төркеме җитәкчеләре тарафыннан үткәрелүе тора. Әлеге модельне характерлап торучы сыйфатлар: баланың белем бирү учреждениесендә көн буе булуына яхшы шартлар тудыру; белем бирү учреждениесенең тәрбия бирү һәм төп белем бирү программасы кысаларында белем бирү, тәрбия бирү һәм үстерү процессларының эчтәлек ягыннан берлеге; санитар-эпидемиологик кагыйдәләрне һәм нормаларны үтәүне тәэмин итә торган сәламәтлекне саклау тирәлеге булдыру; балаларның үзбилгеләнеше өчен шартлар тудыру; төп һәм өстәмә белем бирү программаларының интеграциясенә таяну.

Көне буена сузылган белем бирү процессын уңышлы тормышка ашыру өчен шартлар комплексын булдыру (өстәмә белем бирүне дә, сәламәтлекне саклау шартларын да кертеп) әлеге модельнең өстенлеге булып тора.

Инновация — белем бирү моделе. Инновация — белем бирү моделе гомуми белем бирү учреждениеләренең өстәмә һөнәри педагогик белем бирү учреждениеләре, югары һөнәри белем бирү учреждениеләре, фәнни оешмалар, муниципаль методик хезмәт белән тыгыз мөнәсәбәттә эшли.

Дәрестән тыш эшчәнлек — ул төп гомуми белем бирүгә ниндидер механик өстәлмә генә булмыйча, сәләтле балалар яки өлгерәүчеләр белән эш оештыруга гына кайтып калмыйча, һәрбер баланың сәләтен, кызыксынуларын ача торган иҗат дөньясы булуын истә тотарга кирәк.

ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕК АША ТУГАН ТЕЛНЕ (ТАТАР ТЕЛЕН) һӘМ ӘДӘБИЯТНЫ УКЫТУНЫ НЫГЫТУ МӨМКИНЛЕКЛӘРЕ

Бүгенге көндә гомуми белем бирү мәктәбен дәресләрдән тыш эшчәнлектән башка күз алдына да китереп булмый. Укыту һәм тәрбия бирү эшендә дәресләрдән тыш эшчәнлекнең төрле формаларын куллану укучыда татар теле һәм әдәбиятын өйрәнүгә карата кызыксынуны көчәйтә, аңа коммуникатив компетенцияләрен формалаштыруда, сыйфатлы белем алуда, сәләтләрен үстерүдә, шәхси ихтыяҗларын канәгатьләндерүдә яңа мөмкинлекләр тудыра. Дәрестән тыш эшчәнлекнең гомуми системасында мөһим урынны тел һәм әдәбият укытучыларының эшчәнлеге алып тора. Бу эшчәнлек укытучыга предмет буенча белемнәрне ныгытырга, предметка карата кызыксыну уятырга, укучыларның иҗади сәләтләрен үстерергә ярдәм итә, мөстәкыйль фәнни-тикшеренү эшчәнлегенә әзерли, укучыларның мәдәни дәрәҗәсен арттыра, эстетик зәвык барлыкка китерә.

Дәрестән тыш эшләр төрле формаларда була. Кайберләре уку елы буена, хәтта берничә ел системалы рәвештә оештырыла: түгәрәкләр, клублар, студияләр. Эпизодик рәвештә уздырыла торган формалар да бар: олимпиада, әдәбият, китап атналыгы, декада һәм айлык, төрле кичәләр һәм иртәләр, радио тапшырулар, экспедиция һәм экскурсияләр, күргәзмәләр оештыру. Аерым эш формалары язма рәвештә башкарылалар: стена газетасы, бюллетень чыгару, кулъязма, альбом яки журнал хәзерләү.

Дәрестән тыш эшләрдә катнашуның төп мотивы — кызыксыну. Ләкин кайсы формасы гына оештырылмасын, максат-бурычлар, эшнең эчтәлеге, оештырылу үзенчәлеге алдан билгеләнеп, катнашучыларга аңлатылырга тиеш.

Дәрестән тыш эшләрне уздырганда түбәндәге таләпләрне истә тотарга кирәк:

– дәрестән тыш эшләрдә укучының үз иреге белән катнашуы;

– укучыларны яхшы яки начарларга бүлүдән нык саклану, укучыны, ничек укуына һәм нинди булуына карамастан, дәрестән тыш эшләргә җәлеп итү;

– дәрестән тыш эшләрне әдәбият, тел, рус теле һәм әдәбияты, тарих, сынлы сәнгать, музыка һәм башка предмет дәресләре белән тыгыз бәйләнештә алып бару;

– дәрестән тыш эшләр формасының һәм методикасының мавыктыргыч булуы;

– сайланган эш төрләре, аларның максатлары һәм материаллары укучыларның яшь үзенчәлекләренә яраклы булып, әдәби хәзерлек дәрәҗәләрен истә тотып оештыру;

– дәрестән тыш эшләрне дәресләр белән тыгыз бәйләнештә алып бару, ләкин алар укучыларның мөстәкыйльлеге, иҗади активлыгы,

материаллар күплеге белән аерылып торырга, бизәкле һәм эмоциональ рәвештә, зур җанлылык белән үткәрелергә тиеш.

Тирәнтен белем-тәрбия бирүнең бер юнәлеше — укучыларны *олимпиадаларга әзерләү*. Мәктәп укучылары олимпиадасы — укучыларны теге яки бу предметны өйрәнүгә кызыксыну тудыру, укучылар һәм укытучыларның белем дәрәҗәсе өчен җаваплылык хисен арттыру, бер-берең белән ярышу мохитен тудыру, гадел көндәшлек булдыру, укучыларның интеллектуаль мөмкинлекләрен тормышка ашыру, өстәмә белем бирүнең барлык эш төрләре буенча нәтиҗә ясау максатыннан оештырыла торган чара.

Олимпиада — теге яки бу предмет буенча дәрестән тыш массакүләм чаралар арасында иң киң кулланылыштагы төр. Ул укучыларны яңа заман шартларында һәм, иң мөһиме, конкуренция шартларында яшәргә өйрәтергә булыша. Бүгенге көндә укучыларның олимпиадаларда катнашу нәтиҗәләре мәктәптә, шәһәрдә, республикада белем бирү дәрәҗәсен ачыклый торган бер критерий булып тора, укытучының эшчәнлек дәрәҗәсен бәяләргә ярдәм итә.

Укучыны олимпиадага әзерләү нигезендә системалылык, эзлеклелек ятарга тиеш: мондый төр ярышларга укучыны башлангыч сыйныфлардан ук әзерләү мөһим. Өченче сыйныфта мәктәп күләмендә еллык олимпиадалар уздырып карарга мөмкин. Призлы урыннарга лаек булган укучылар параллель сыйныфта белем алган җиңүче балалар белән үзара көч сынашалар. Жюри һәр катнашучының эшен тикшерә, анализ ясый һәм төрле номинацияләр буенча җиңүчеләрне билгели, мәсәлән, «Татар теленең иң яхшы белгече», «Иң яхшы филолог» һ.б. Олимпиадада катнашкан укучы үз җиңүләрен, төрле бәйгеләрдә катнашкан мәгълүматларны бер папкага туплап барса, алга таба кулайрак була. Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар теленнән республика олимпиадасы 3 этапта уздырыла: мәктәп, муниципаль һәм республика турлары.

Тирәнтен белем-тәрбия бирүнең тагын бер әһәмиятле юнәлеше — укучыларның *фәнни-тикшеренү эшчәнлекләре* белән җитәкчелек итү, аларны фәнни-гамәли конференцияләргә әзерләү. Фәнни-тикшеренү эшен башкару дәвамында укучыда да, укытучыда да фәнгә кызыксыну уяна. Укучының логик фикер йөртү сәләте арта, ул фәнни әдәбият белән кызыксына, эзләнә. Фәнни-практик конференцияләрдә катнашу, чыгыш ясау шәхестә максатчанлык, төгәллек, җаваплылык һәм ихтыяр көче тәрбияли.

Гомуми мәктәптә укучыларның тикшеренү эшчәнлеген шартлы рәвештә 2 төргә бүлеп карап була:

1) фәнни-тикшеренү эшчәнлеге;

2) проект эшчәнлеге.

Укучыларның фәнни-тикшеренү эшчәнлегендә билгеләнгән тема буенча тикшеренү бурычын, проблемасын кую, шул проблемага

караган теорияне өйрәнү, методиканы сайлау, материал туплау, анализ ясау һәм гомумиләштерү, фәнни комментарийлар бирү һәм нәтиҗәләр чыгару күздә тотыла. Барлык фәннәрдән дә фәнни-тикшеренү эшчәнлеге шушы әйтеп үткән структурага нигезләнә.

Проект эшчәнлеге — укучыларның бердәм уку-танып белүгә юнәлдерелгән, иҗат итүгә корылган яки уен эшчәнлеге, аның гомуми эшчәнлек нәтиҗәсенә юнәлдерелгән максаты, тикшеренү методлары, эш төрләре була. Проект эшендә килеп чыгачак ахыргы продукт турында алдан күзаллау була, ул эшнең кереш өлешендә гипотеза дип билгеләнә. Проект эшен башкару проектлау этапларыннан тора, ул үз эченә концепцияне язуны, максат-бурычларны күрсәтүне, эшчәнлекнең оптималь ресурсларын табуны, эш планын яки программасын төзүне, проектны тормышка ашыру буенча эшне оештыруны, эшчәнлек нәтиҗәсенә рефлексия ясауны күздә тота.

Ярдәмлекнең кушымта өлешендә эш программасы, дәрестән тыш чара үрнәкләре, дәрестән тыш эшчәнлекнең бер төре буларак проект эше темалары тәкъдим ителә.

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. 2018/2019 нчы уку елында «Туган тел (татар теле) һәм «Туган тел әдәбияты (татар әдәбияты) укытуның актуаль мәсьәләләре / Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р.Р., Фәттахова Р.Ф., Гыйләҗева Л.Г., Һадиева Г.В. — Казан: ТРМҮИ, 2018. — 48 б.

2. Заманча технологияләргә нигезләнгән татар теле һәм әдәбияты дәресләре (ТР Лаеш муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эш тәжрибәсеннән) / Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р.Р., Мөхәрләмова Г.Н., Һадиева Г.В. — Казан: ТРМҮИ, 2016. — 88 б.

3. Методические рекомендации по предодаванию предметов «Татарский язык и литература» / Сост.: Шамсутдинова Р.Р., Фаттахова Р.Ф. — Казан, ТРМҮИ, 2017. — 39 б.

4. Методические рекомендации по составлению рабочих программ для 7 классов общеобразовательных организаций (с обучением на русском языке) / Сост.: Мухарлямова Г.Н., Фаттахова Р.Ф., Сиразетдинова З.П. и др. — Казан, ТРМҮИ, 2017. — 44 б.

5. Методические рекомендации по составлению рабочих программ для 7 классов общеобразовательных организаций (с обучением на татарском языке) / Сост.: Мухарлямова Г.Н, Гилязова Л.Г., Валиева М.Н. и др. — Казан, ТРМҮИ, 2017. — 39 б.

6. Методические рекомендации по составлению рабочих программ для 7 классов общеобразовательных организаций (с обучением на русском языке для изучающих татарский язык как родной) / Сост.: Мухарлямова Г.Н, Хадиева Г.В., Ханнанова М.Х. и др. — Казан, ТРМҮИ, 2017. — 67 б.

7. Рус телендә сөйләшүче укучыларга татар теле буенча олимпиадага әзерләнү өчен биремнәр / Төзүче: Р.Р. Шәмсетдинова. — Казан, 2016. — 17 б.

8. Сборник заданий школьного, муниципального и республиканского туров олимпиад по татарскому языку для русскоязычных обучающихся / Сост.: Шамсутдинова Р.Р., Фаттахова Р.Ф., Гилязова Л.Г., Хадиева Г.В. — Казан, ТРМҮИ, 2017. — 33 б.

9. Сборник КИМ для мониторинга знаний обучающихся русскоязычных групп 4, 6, 8 классов по татарскому языку / Сост.: Шамсутдинова Р.Р., Фаттахова Р.Ф., Гилязова Л.Г., Хадиева Г.В. — Казан, ТРМҮИ, 2017. — 39 б.

10. Сборник текстов и заданий для проведения контрольных работ по татарскому языку / Сост.: Шамсутдинова Р.Р., Фаттахова Р.Ф., Гилязова Л.Г., Хадиева Г.В. — Казан, ТРМҮИ, 2017. — 28 б.

11. Современные технологии в обучении татарскому языку и литературе / Сост.: Шамсутдинова Р.Р., Зиннатуллин Р.К., Фаттахова Р.Ф., Гилязова Л.Г., Хадиева Г.В. — Казан, ТРМҮИ, 2017. — 94 б.

12. Татар телен өйрәнү өчен укучыларны төркемнәргә бүлү буенча тәкъдимнәр: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларының I сыйныфлары өчен. Татар телен һәм әдәбиятын укытуда уен технологияләре (ТР гомуми белем бирү оешмаларының татар теле һәм

әдәбияты укытучыларының эш тәҗрибәсеннән) / Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р.Р., Фәттахова Р.Ф., Мөхәрләмова Г.Н., Һадиева Г.В. — Казан: ТРМҮИ, 2016. — 23 б.

13.Татар телен һәм әдәбиятын заман таләпләре буенча укытабыз (ТР Бөгелмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының тәҗрибәсеннән / Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р.Р., Мөхәрләмова Г.Н., Һадиева Г.В., Мәхмүтова Ф.Т. — Казан: ТРМҮИ, 2015. — 160 б.

14.Татар телен һәм әдәбиятын укытуда коммуникатив технологияләр (ТР гомуми белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эш тәҗрибәсеннән) / Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р.Р., Фәттахова Р.Ф., Мөхәрләмова Г.Н., Һадиева Г.В. — Казан: ТРМҮИ, 2016. — 53 б.

15.Татар телен һәм әдәбиятын укытуда уен технологияләре (ТР гомуми белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эш тәҗрибәсеннән) / Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р.Р., Фәттахова Р.Ф., Мөхәрләмова Г.Н., Фәттахова Р.Ф., Һадиева Г.В. — Казан: ТРМҮИ, 2016. —55 б.

16.Шамсутдинова Р.Р. Методические рекомендации по подготовке к олимпиадам по татарскому языку русскоязычных учащихся. — ТРМҮИ, 2016. — 36 б.

17.Эш программаларын төзү буенча методик тәкъдимнәр (5 нче сыйныф өчен «Татар әдәбияты» предметы буенча эш программасы). — Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2015. — 94 б.

18.Эш программаларын төзү буенча методик тәкъдимнәр (5 нче сыйныф өчен «Татар теле» предметы буенча эш программасы). – Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2015. — 136 б.

19.Эш программаларын төзү буенча методик тәкъдимнәр (6 нчы сыйныф өчен «Татар теле», «Татар әдәбияты» буенча эш программалары). 1 кисәк. —Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2016. — 108 б.

20.Эш программаларын төзү буенча методик тәкъдимнәр (6 нчы сыйныф өчен «Татар теле», «Татар әдәбияты» буенча эш программалары). 2 кисәк. — Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2016. — 108 б.

Кушымта 1

Низамиева Лилия Назыйм кызы,
Казан шәһәре Идел буе районы ГББМУ "6 нчы гимназия" нең
беренче квалификацион категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

5нче СЫЙНЫФНЫҢ ТАТАР ТӨРКЕМЕ ӨЧЕН ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕК ПРОГРАММАСЫ

"ХАЛЫК ҖӘҮһӘРЛӘРЕ"

Аңлатма язуы

5нче сыйныф өчен дәрестән тыш эш программасы татар халык авыз иҗаты төрләрен, аларның яшь үзенчәлегенә туры килерлек үрнәкләрен үз эченә ала. Бу темалар балаларның телне үзләштерү дәрәҗәсенә туры килерлек итеп, метапредмет бәйләнешләрне, уку процессындагы логик эзлеклелекне искә алып сайланган һәм сәгатьләргә бүленгән.

Халык авыз иҗаты баланы сәнгать дөньясына җәлеп итү, халыкның традицияләре белән таныштыру өчен иң кулай материал булып кына калмый, образлы фикерләү үстерү, эстетик кыйммәтләргә уңай караш тудыруда да зур ярдәм итә. Туган халкы авыз иҗаты әсәрләре баланы бишектән алып озатып килсә, күрше халык иҗаты үрнәкләре аңа дөньяны танып белергә, толерант шәхес булып формалашырга зур ярдәм итә.

Белем бирү процессын халыкның күпьеллык традицияләренә нигезләнеп кору бүгенге көндә иң актуаль мәсьәләләрдән санала, чөнки халык җырлары, әкиятләре, уеннары, мәкаль һәм әйтемнәре баланың рухи-эстетик үсешендә төп рольне уйный, тормышны аңлауда һәм аңа яраклашуда зур ярдәм итә.

Максатлар:

1.Укучыларның әдәбият дәресләрендә алган белемнәрен ныгыту, тирәнәйтү.

2.Балаларга үз халкының милли һәм рухи байлыкларын өйрәтү; киләчәктә халкыбызның йола-бәйрәмнәрен, җырларын, гореф-гадәтләрен торгызуга күпмедер нигез, таяныч булырлык белемнәрне бирү; эстетик зәвыклы, креатив, иҗади шәхес тәрбияләү.

Бурычлар:

– татар халык авыз иҗаты тарихы, жанрлары, халыкның милли киемнәре белән танышу;

– халык традицияләренә, костюмына, милли мирасына кызыксыну хисләре, хөрмәт уяту;

– балаларның иҗади сәләтләрен үстерү.

Эш барышында 5нче сыйныф балаларының яшь үзенчәлекләренә туры килә торган төрләргә зуррак урын бирү күздә тотыла. Бу — уеннар, җырлар, әкиятләр сәхнәләштерү, рәсемнәрен ясау, табышмаклар өйрәнү, иҗат итү.

Укытуның шәхескә кагылышлы нәтиҗәләре

Гомуми белем бирү мәктәбен тәгәлләгәндә, укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата түбәндәге **шәхси кыйммәтләре формалашкан булуы күзаллана:**

– шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;

– әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;

– текстлардагы төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;

– «гаилә», «туган ил», «мәрхәмәтлелек» төшенчәләрен кабул итү, «башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык», «кеше кадерен белү» кебек хисләр формалашу.

Универсаль уку гамәлләре формалаштыру буенча буенча планлаштырыла торган нәтиҗәләр

Урта белем бирү баскычында телгә өйрәтү, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен ***(танып белү, регулятив, коммуникатив)*** формалаштыруга хезмәт итә.

Танып белү универсаль уку гамәлләре:

– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;

– объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;

– төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү.

Регулятив универсаль уку гамәлләре:

– уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;

– эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;

– укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;

– ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;

Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:

– әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;

– әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;

– аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);

– парларда һәм күмәк эшли белү;

– мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;

– әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

Предмет нәтиҗәләре

Тыңлап аңлау:

– төрле жанрдагы халык авыз иҗаты әсәрләрен тыңлап аңлау;

– тәкъдим ителгән текстны тыңлап, эчтәлеге буенча сорау бирә, сорауларга җавап бирә белү;

– зур булмаган халык авыз иҗаты әсәрләреннән өзекләрне, тыңлап аңлап, эчтәлеге буенча фикереңне әйтә, аралаша белү;

– сыйныфташларыңның сөйләмен тыңлап аңлау һәм аларга үз фикереңне аңлата белү, алар белән әңгәмә кору, әңгәмәдә катнаша белү.

Диалогик сөйләм:

– сорау, җавап, килешү-килешмәү, шикләнү һәм башка репликаларны дөрес кулланып, әңгәмә кору;

– парда, төркемдә сөйләшү барышында үз фикереңне аңлата, раслый, дәлилли белү, ситуация аңлашылмаганда, сорау биреп, сөйләм барышын ачыклый белү.

Монологик сөйләм:

– халык авыз иҗаты әсәрләре үрнәгендә әкиятләр,табышмаклар һ.б. төзи алу һәм аның эчтәлеген сөйли белү;

– конкрет ситуациягә үз карашыңны әйтә, төрле вакыйгалар, яңалыкларны хәбәр итә белү.

Форма һәм методлар

Әгәр дә без сөйләүчене нәтиҗәле, ышандырырлык, юатырлык, тынычландырырлык яки нинди дә булса гамәл белән җәлеп итәрлек дәрәҗәдә аралашырга өйрәтергә телибез икән, балалар дәреслеләрдә үзләре күбрәк сөйләшергә тиешләр. Моның өчен, балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, түбәндәгеләр кулланыла:

– уеннар;

– китапханәдә өстәмә әдәбият белән эш;

– әңгәмә;

– әкиятләр сәхнәләштерү;

– экскурсияләр (мөмкинлек буенча);

– кичәләр, бәйрәмнәр;
– ата-аналар һәм әби-бабайлар белән берлектә иҗади биремнәр үтәү.

Балаларның матур әдәбият һәм халык авыз иҗаты белән кызыксынуларын, иҗади сәләтләрен, мөстәкыйль фикерләү, фикерләрен дәлилли алу осталыгын үстерү һәм тирәнтен өйрәтү максатыннан, түбәндәге материаль-техник чараларны файдалану мөмкинлеге күздә тотыла:

– халык авыз иҗаты үрнәкләре;
– тарихи чыганаклар;
– сынлы сәнгать әсәрләре;
– тема буенча музыкаль әсәрләр;
– күрсәтмә әсбаплар;
– мультимедиа укыту программалары;
– электрон дәреслекләр;
– Интернет материаллары;
– электрон китапханә;
– компьютер программалары;
– укучыларның белемнәрен тикшерү программалары;
– сүзлекләр;
– белешмә материаллар;
– татарча сайтлар: ”Тазбаш”, “Белем.ру”, “Татарча мультфильмнар”, “Сабыйга”;
– балалар өчен чыгарылган газета һәм журналлар;
– яңа әдәби китаплар;
– аудио-һәм видеоәсбаплар;
– интерактив тикшерү программалары.

Программаның эчтәлеге

№	Тема	Сәг. саны
1-2	Балалар фольклоры. Балалар фольклоры турында төшенчә бирү, китаплар белән таныштыру.	2
3	Тизәйткечләр, тел шомарткычлар.	1
4	Сынамышлар, санамышлар.	1
5	Табышмак әйтәм- җавабын тап.	1
6	Такмаклар, такмазалар.	1
7	Мәкальләр һәм әйтемнәр.	1
8	Мәсәлләр.	1
9	Әкиятләрнең төрләре.	1
10	Татар халык әкиятләре.	1
11	Автор әкиятләре.	1

12	Әкият сайлап алып сәхнәләштерү.	1
13	Курчак театры оештыру.	1
14	Әкиятләр кичәсе.	1
15	Әкият язып карыйбыз.	1
16	Татар театрлары турында әңгәмә.	1
17	Татар театрларының берсенә сәяхәт.	1
18	Бәетләр.	1
19	Мәзәкләр.	1
20	Татар-халык җырлары.	1
21	Җырларның төрләре.	1
22	Бишек җырлары.	1
23	Татар халык бәйрәмнәре турында мәгълүмат бирү.	1
24	“Сөмбелә” бәйрәме.	1
25	“Нәүрүз” бәйрәме.	1
26	“Карга боткасы”.	1
27	“Сабантуй” бәйрәме.	1
28	Татар исемнәре ни сөйли?	1
29	Шәҗәрә төзү.	1
30	Татар халкының милли киемнәре.	1
31	Татар халык ашлары турында әңгәмә оештыру.	1
32	Милли музейга сәяхәт.	1
33	Минем беренче шигырем.	1
34	Татарстандагы әдәби музейлар.	1
35	Татар әдәби музеена сәяхәт. (М. Җәлил, Г. Тукай, С. Хәким, К. Насыйри)	1

Кушымта 2

ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ) ҺӘМ ӘДӘБИЯТ БУЕНЧА ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЧАРА ҮРНӘКЛӘРЕ

Низамиева Лилия Назыйм кызы,
Казан шәһәре Идел буе районы ГББМУ "6 нчы гимназия"нең
беренче квалификацион категорияле
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

«ТЕАТР ЯКТЫЛЫККА, НУРГА ИЛТӘ!»

Дәрестән тыш чара

Максат: укучыларның әдәбият дәресләрендә алган халык авыз иҗатының кыска жанрлары турындагы белемнәрен ныгыту, тирәнәйтү.

Бурычлар:

1.Психологик барьерларны киметү ярдәмендә коммуникатив компетенцияләрен формалаштыру.

2.Татар театры белән кызыксыну булдыру.

3.Фольклорның кыска жанрлары — мәкаль, әйтем, тизәйткечләр турында белемнәрне активлаштыру.

Көтелгән нәтиҗәләр:

Шәхскә кагылышлы нәтиҗәләр

1.Патриотик хис, туган илгә, Татарстанның күпмилләтле халкының үткәненә һәм хәзергесенә хөрмәт тәрбияләү; үзеңнең этник чыгышыңны, үз халкыңның телен, әдәбиятын, мәдәниятен белү;

2.Башка кешегә, аның фикеренә, дөньяга карашына, мәдәниятенә, теленә ихтирамлы мөнәсәбәт формалаштыру;

Метапредмет нәтиҗәләр

1.Регулятив — планлаштырылган нәтиҗәләр белән үз гамәлләреңне тәңгәлләштерә белү, нәтиҗәләргә ирешү процессында эшчәнлекне контрольдә тоту, тәкъдим ителгән шартларда һәм куелган таләпләрдә гамәлләр ысулын билгеләү, үзгәреп торган ситуацияләрдә гамәлләргә коррекция кертү.

2.Танып-белү — төшенчәләрне билгели, гомумиләштерә, аналогияләр таба, төркемнәргә бүлә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен күрсәтә, логик фикерләр төзи, нәтиҗә ясый алу.

3.*Коммуникатив* — сыйныфташлар белән уку эшчәнлеген оештыра, төркемдә һәм үзаллы эшли, үз фикереңне формалаштыра, аргументлаштыра һәм аны яклый белү.

Предмет нәтиҗәләре

1. Халык авыз иҗатының кыска жанр әсәрләренә (мәкаль, әйтем, тизәйткеч) кызыксыну булдыру. Татар театрлары турында мәгълумат бирү.

2. Актив һәм потенциаль сүзлек запасын баету, аралашу стиленә һәм ситуациясенә ярашлы туган телдә хисләрне һәм уйларны иркен белдерү өчен сөйләмдә кулланылучы грамматик чараларның күләмен киңәйтү.

Юнәлеше: гомуммәдәни.

Формасы: театр остаханәсе.

Җиһазлау: проектор; экран; аудиоязмалар; конвертларда мәкальләр, әйтемнәр, тизәйткечләр; әкият геройларына костюмнар.

Дәрестән тыш эшчәнлек барышы:

I. Оештыру, мотивлаштыру

— Исәнмесез, балалар!

Экранга карагыз әле, сез анда нәрсә күрәсез?(театрлар) *(1 нче слайд)*

— Ә нәрсә соң ул театр? (ул-төрле драма әсәрләрен уйный торган урын.)

— Ә безнең шәһәребездә нинди театрлар бар? (Г. Камал, К. Тинчурин, "Әкият" курчак театры, Г. Кариев исемендәге яшьләр театры, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры.)

II. Белемнәрне актуальләштерү.

— Укучылар ә сез беләсезме, татар театрына ничә яшь?

Әйдәгез бергәләп тыңлыйк. АУДИО

— Димәк, татар театрына 112 яшь. Ә иң беренче татар театр труппасы "СӘЙЯР" дип аталган. Ләкин беренче театр куелуга кайбер кешеләр, бигрәк тә олы яшьтәге кешеләр, муллалар каршы булалар. Ләкин соңыннан театрның яхшылыкка өйрәткәнен белгәч үзләре дә театрга йөри башлаганнар. *(2 нче слайд)*

Ә 2019 нчы ел — Россия күләмендә театр елы дип игълан ителде.

— Ә театрда кемнәр эшли? (саныйбыз)

III. Уку мәсьәләсен кую.

— Ә хәзер без сезнең белән укучылар түгел, артистлар һәм режиссёрлар булабыз. (Шарфлар өләшү.)

Биремнәрне бик тырышып эшләргә кирәк булачак, чөнки тормышта артистлар режиссёрга ошарга тырышалар, чөнки рольне аларга режиссёр бирә. Режиссёрлар шулай ук әйбәт булырга тырышалар, чөнки алар әйбәт булсалар аларга яхшы, талантлы артистлар киләчәк.

Төркемгә бүленеп утыралар (артистлар һәм режиссёрлар).

1 нче бирем Театр кешеләренең дикцияләре, сөйләмнәре бигрәк тә матур булырга тиеш. Шуңа алар көн саен тизәйткечләр әйтеп, телләрен шомартып торалар.

– Монда нинди тизәйткеч яшеренгән? *(3 нче слайд)*

Дөрес, әйдәгез бергә укыйк.

Тизәйткечне укыйбыз.

Мич башында биш мәче,
Биш мәченең биш башы.
Биш мәченең биш башына,
Ишелмәсен мич ташы.

— Ә хәзер безгә куллар булыша. (Тизәйткечне әйткәндә куллар белән тезләргә төрле ритм белән сугып кабатлыйбыз.)

— Ә хәзер аяклар да булыша. (Алдагылары кала һәм шул ук вакытта аяклар белән дә тыпырдап кабатлыйбыз.)

— Кем тизәйткечне үзе әйтеп карарга тели? (Балалар әйтеп карый.)

IV. Төркемнәрдә эшләү.

2 нче бирем — чын сәхнә остасы булыр өчен, дөрес интонация белән дә әйтә белергә кирәк. *(4 нче слайд)*

Режиссерларга — мәкальләр, ә артистларга — әйтемнәр бирелә. Сез аларны төрле интонация һәм кәеф белән әйтергә тиеш буласыз.

МӘКАЛЬЛӘР

— Нәрсә сон ул мәкаль? (Балалар җавабы. **Мәкаль** — сөйләшкәндә сүзгә ямь һәм куәт бирү өчен, көнкүрештә күп сыналган дәлил яки шигъри бер мисал урынында әйтеп йөртелә торган, кыска, ләкин тирән мәгънәне эченә алган төгәл җөмләле халык әсәре.)

Телләр белгән — илләр гизгән.
1. Акыллы бабай булып әйтергә.
2. Кечкенә малай булып әйтергә

Күп укыган күп белер.
1. Шатлыклы итеп әйтергә
2. Күңелсез итеп әйтергә

Дус акчадан кыйммәт.
1. Командир булып әйтергә
2. Курка-курка әйтергә

Әни йорты-алтын бишек.
1. Пышылдап әйтергә
2. Кычкырып әйтергә

ӘЙТЕМНӘР

Нәрсә ул әйтем? (Балалар җавабы.)

Соң булса да уң булсын.
1. Көлә-көлә әйтергә
2. Елый-елый әйтергә

Кечкенә дә төш кенә
1. Сорау интонациясе белән әйтергә
2. Гаҗәпләнеп әйтергә

Ике кулга бер эш.
1. Әби булып әйтергә
2. Кечкенә бәби булып әйт

Юлыңа ак җәймә.

1. Шигырь укыган шикелле әйт

2. Әкрен, сузып әйт.

— Молоды! Режиссёрлар, сезгә бу артистлар ошадымы? Артистлар, ә сезгә режиссёрлар ошадымы?

V. Парларда эшләү.

3 нче бирем.

ПАНТОМИМА. Бу биремне сез парларда эшләрсез.

Нәрсә ул беләсезме? Бер сүз дә әйтмичә, нәрсәне дә булса хәрәкәтләр ярдәмендә күрсәтү.

(Балык тотучы, мода күрсәтүче, футбол уйнаучы, кар көрәүче, җырчы, биюче, чаңгычы, йөзүче.)

Балалар парлап пантомималар күрсәтәләр, калганнар аларның кемне күрсәткәнен аңлап алырга тиешләр.

Молодцы! Барысын да бик яхшы башкарып чыктыгыз.

Спектакль әзерли башлагач, артистлар һәм режиссёрлар бергә эшлиләр.

VI. Укучыларның мөстәкыйль эшчәнлеге.

Кемнең бейджигы зәңгәр төстә, минем янга килегез. Сез хәзер бер театрда эшләүче артистлар һәм режиссёрлар. Бу конвертта сез куярга тиешле ***әкият.***

Рольләрне бүлегез. Әзерләнегез.

1. Сертотмас үрдәк

Кемнең бейджигы яшел төстә — сез икенче театрдгы артистлар һәм режиссёрлар буласыз. Сезгә икенче әкият бирелә.

2. Шалкан.

VII. Рефлексия.

Әкиятләрне күрсәтү.

— Молодцы! Барысын да бик яхшы башкарып чыктыгыз.

VII. Йомгаклау.

— Укучылар, театр безнең туган телебезнең сагында тора. Шуңа күрә әти-әниләрегез белән, сыйныфыгыз белән күбрәк татар театрларына йөрегез. Шул очракта, сез туган телебезне беркайча да онытмассыз. Ә хәзер әйдәгез Татар халкының гимнына әверелгән “Туган тел” җырының бер куплетын бергәләп башкарыйк.

Бергә “Туган тел” җыры башкарыла.

— Дәрес тәмам. Сау булыгыз.

Шәрипова Чулпан Рәмзил кызы,
Әһлетдинова Ландыш Филүс кызы,
Актаныштагы "Сәләтле балалар өчен
гуманитар гимназия-интернат"
ДАГУның татар теле һәм әдәбияты укытучылары

"ЯТИМЛЕКТӘ ҮТКӘН БАЛАЧАК ҖЫРЛАРЫМДА МӘҢГЕ КАЛАЧАК..."

(әдәби-музыкаль кичә)

(*Якташыбыз Әлфия Афзал кызы Афзалованың*
якты истәлегенә багышлана)

Данны иң өстеңдә тотып торыр өчен ныклы тез буыны кирәк.
Татар халык әйтеме

Максат:

1. Укучыларны татар сәнгатенә зур өлеш керткән шәхесләр белән таныштыру.

2. Якташыбыз Әлфия Афзалованың тормыш юлы, иҗаты белән тирәннән танышу.

3. Сәнгатьле уку күнекмәләре булдыру.

Җиһазлау: сәхнә бәйрәмчә бизәлгән: түрдә Ә.Афзалованың портреты, баян, стенада ноталар, шарлар, төрле җырлары яздырылган аудиоязмалар; сул якта экран, анда Ә. Афзалова архивыннан алынган фотосурәтләр; кичәнең башыннан ахырына кадәр вакыйгаларга туры китереп Рабит Батулланың "Моң патшабикәсе" фильмыннан өзекләр куела.

Кичә барышы

Сәхнә түренә бишек эленгән. Экранда бишек тибрәтеп утыручы Ана күренеше. Бишектән сабый бала тавышы ишетелә. Ана кеше сабыр гына килеп, бишекне тибрәтеп җырлый башлый:

Әлли-бәлли итәдер,
Бәләкәй, матур бәбкәем,
Еламаса, йокласа,
Рәхмәт укыр әнкәең...

1 алып баручы. Хәерле көн, хөрмәтле укучылар, укытучылар, кичәбез кунаклары! Актанышыбызның горурлыгы булган Әлфия апа Афзалованың тууына 85 яшьлек юбилей кичәсен ачык дип игълан итәбез!

2 алып баручы. Күпләрнең тормыш маягы, дәрт-дәрман чыганагы булган Әлфия Афзалова 1933 елның 15 гыйнварында Башкортстанның Калтасы районы Кабан авылында туса да, үзенең туган җире итеп Актанышны саный, гомере буе Агыйдел буйларын сагына.

Экранда Әлфия Афзалованың балачагында төшерелгән фотолары. Сәхнәгә җитәкләшеп, кулларына чүпрәк курчак тоткан,

ярлы гына киенгән Әлфия (5-6 яшьләрдә) һәм сеңлесе Флүрә (2-4 яшьләрдә) чыга. Әлфия: “Мин үзем биш яшьлек сабый гына булсам да, тормышның бөтен тирәнлеген күрмәсәм дә, күп нәрсәне аңлыйм. Ике яшьлек сеңлем Флүрә белән мич башында уйнарга яратабыз, чөнки анда җылы, ышанычлы. Өс-баш ярлы, шулай да әниебез чәчләребезне пөхтә итеп үрә, кулларыбызга да үзе теккән чүпрәк курчаклар. Әтиебез өйгә кайтып кергән минутларны беркайчан да онытырлык түгел. Ачылган ишектән өйгә салкын кереп тула. Әтиебез холыксыз булганлыктан әниебезне еш кыйный. Әни! Әнием!.. Әти, тимә, тимә әниебезгә!.. Кечкенә кулларыбыз белән җан тырмашып әнине араларга азапланулары бызда, бәгырьне өзеп алырлык бер хис — барысы бергә бутала. Шунда күңелләрнең ничек өзгәләнгәнен белсәгез икән!.. Безгә — бер-бер артлы якты дөньяга килгән өч кыз балага, ягъни миңа, Флүрәгә һәм Гөлсирингә ятимлек ачысы, тормыш михнәте алдан ук әзерләп куелган икән”.

Татар халык җыры “Шахта”

(Әлфия Афзалованың кечкенәдән яратып башкарган җыры)

1 алып баручы. Шулкадәр тирән моң, хисле күңел каян килгән соң безнең Әлфиягә? Мөгаен, ятимлектәндер. Әлфия апа Афзалованың ятим балачагын, ачы тормыш юлын күпләр Тукаебыз белән янәшә куя. Тиф белән авырган әнисе Миңямал да яшәр иде, бик яшәр иде балалары янәшәсендә. Кызы Әлфиянең татарның күгендә йолдыз булып балкыганын күреп, һичшиксез, сөенер, горурланыр иде. Тик... күпләргә тормыш аяусыз шул...

2 алып баручы. Башта газиз әниләрен, соңрак кечкенә сеңелләре Гөлсиринне югалткан, үзләре дә беркатлы сабыйлар булган Әлфия белән Флүрәгә берникадәр вакыт үз көннәрен үзләренә күрергә туры килә. Хәтта бераз хәер сорашырга да туры килгән аларга. Шулай ачлыктан котылып калганнар алар. Ә Актанышта әниләренең бертуган сеңлесе Закирә апалары яшәгәнен ул вакытта ишетеп кенә белә сабыйлар...

1 алып баручы. Яңа Кабан авылы халкы гомер-гомергә Актанышка базарга йөргән. Чабата үреп, төрле кирәк яраклар ясап, базарга илтеп сатып гомер күргән ярлы халык.

Сәхнәдә базар күренеше. (Рольләр: Закирә апа (Җыракай) — әнисенең апасы, Кабан кешеләре). Экранда татар базарыннан бер күренеш, сәүдә рәтләре арасында татар сәүдәгәрләре сату-алу белән шөгыльләнә.

Закирә апа. Монда Яңа Кабаннар бармы? (*кычкырып*)

Халык. Бар Кабаннар, менә без Кабанныкы.

Закирә апа. Минем Миңямал атлы сеңлем яман авырудан вафат булган, өч баласын калдырып... Ул балалар исән микән? Ни хәлләре бар микән?

Халык. Әтиләре дә күренми, әллә кая киткән, балалар җитәкләшеп урамда йөриләр, ачтан үлмәсәләр ярар инде...

Закирә апа. Икенче атнага базарга килсәгез, шул балаларны саламга булса да төреп алып килегезче, зинһар! *(елый-елый үтенә)*

Халык арасыннан бер абзый. Нинди дә булса чарасын табармын, икесен дә төреп алып килермен!

1 алып баручы.

Бармыни безнең татарның
Хәсрәтсез торган чагы?!
Хәсрәтне оныттыра кайчак
Моңлы Актаныш ягы.

Роберт *Әхмәтҗан.*

Әйе, саламга төренеп килгән балаларның сагышын Актаныш бераз онытгырып торгандай була. Ләкин алда яңа сынау көтеп торган икән үзләрен. Җыракайның өенә аяк басуга бәхеттән, ризык исеннән, җылы өй күренешеннән башлары әйләнеп китә сабыйларның. Мондый рәхәтне күргәнмени соң бу гөнаһсыз балалар?! Ләкин җизни тиешле кешенең генә бораулап каравыннан, кызларны "артык кашык" күрүеннән бәхетнең бер чите "кителә". Нәкъ шушы вакытта апа-сеңелнең юллары аерыла да инде... Флүрә Такталачык балалар йортына җибәрелә, Әлфия апасында кала. Ерак киләчәктә үзенең ике баласы өстенә сеңлесе Флүрәнең алты баласын үз канаты астына алачагын каян белсен соң нәни Әлфия?!

2 алып баручы. 1939 елда Әлфия апа Афзалова беренче класска укырга керә. Ниндидер якты, татлы, серле мизгелләр биләп ала аның күңелен. Кечкенәдән моңга, сәнгатькә гашыйк булып үскән кыз бала җыр дөньясына кереп чума.

Сәхнәдә мәктәп күренеше. Җыр дәресе бара. Укучылар арасында кечкенә Әлфия дә бар. Экранда агачтан салынган ярлы авыл мәктәбеннән бер күренеш. (Рольләр: Нәфисә апа –- җыр укытучысы, Әлфия –- беренче класс укучысы, укучылар)

Нәфисә апа. Балалар, без алдагы дәрестә М. Җәлил шигыренә Җәүдәт Фәйзи көй язган "Мияу, мияу, пескәем!" дип аталган җыр өйрәндек. Әлфия, бас әле, бу җырны кабатлап җырлап күрсәт әле?

Әлфия. *(урыныннан торып баса, һич ялгышмыйча җырны җырлый)*

Чоландагы ак майга
Ияләшкән күселәр,
Мин чоланны сакларга
Куштым ала песигә:
— Мияу, мияу, пескәем!
Барчы, зинһар, чоланга,
Майны сакла күседән,
Оясыннан чыгарма!

Нәфисә апа. Балалар, ишеттегезме? Әлфия җырны ничек матур итеп җырлады! Тавышы матур икән. Хәтере дә искиткеч, бер сүзен дә онытмаган. Булдырдың, Әлфия!

Әлфия. Рәхмәт, Нәфисә апа!

1 алып баручы. Беренче класстан ук яратып җырлый торган тагын бер җыры була Әлфиянең. “Карлыгач” дигән спектакльдән Карлыгач исемле җыр ул...

1 укучы. Һаваларда очкан карлыгачлар
Болытларга кереп югала.
Кыз булганчы, булсаң канатлы кош —
Тоткын булмас идем дөньяда.
Түгәрәк күл матур була,
Су белән тулса гына.
Тусын анадан кыз бала,
Бәхете булса гына...

1 алып баручы. Сүзләре дә, көе дә матур булган бу җырны барысы да үз итә. Ләкин Нәфисә апасы җырның сүзләрен түбәндәгечә үзгәртә:

Тусын анадан кыз бала,
Отличник булса гына...

Шул көннән башлап Нәфисә апасы Әлфиягә зур өметләр баглый. Ә Әлфиянең репертуарында укытучы апасы өйрәткән “Шахта”, “Ал Мәрфуга, гөл Мәрфуга”, “Нурия” дигән җырлар пәйда була. Җыр ятим баланың күңелен дәвалый, сагышларын тарата, ачлыкны онытгырып, киләчәккә ымсындыра...

Экранда сугыш күренешләре күрсәтелә.

2 алып баручы. 1941 ел... Маңгайларга сырлар уйган, ягымлы йөзләргә җыерчыклар сызган сугыш... Авылдагы ир-егетләр сугышка китеп баралар. Авыл үзәк өзгеч саубулашу җырларына, хатын-кызларның үксеп-үксеп елаган тавышларына күмелә. Әлфиянең җизнәсе дә сугышка алына һәм сугыш кырларында ятып кала. Әлфия өчен тыныч тормыш башлана. Нәкъ менә шушы мизгелләрдә җырчы кызны җыр бөтенләе белән бөтереп ала. Ул, Актаныш районының агитбригадасы составындагы артистка буларак, авылдан-авылга концертлар куеп йөри башлый. Ә ул вакытта бик популяр булган Зифа Басыйрова, Гөлсем Сөләйманова, Рәшит Баһаповларны, сабый чагыннан ук тыңлап үскәнгәме, үзенең остазлары дип саный.

Татар халык җыры “Өй артында шомыртым”

1 укучы.
Күк капусын гомергә бер
Безгә дә Тәңре ачты, —
Иңдерде Актанышка ул
Иң моңлы сандугачны.
Сүнгән күңелгә сөюне
Ул гына сала икән.
Халыкны бер сандугач та
Юата ала икән!..

Роберт Әхмәтҗан.

1 алып баручы. Әйе, халык күңеленә күп кирәкмени?! Илдә коточкыч сугыш бара, тылда күзгә-күз карашып халык ачлык белән көч сынаша. Ә Әлфиянең җырлары, берничә сәгатькә генә булса да, хыялдагы тормышка илтә, мәхәббәт, дуслык хисләрен яңарта.

2 укучы. *(көй астында сөйли)*

Ник соң моңсу була
Кичен айга карау?
Ник соң йөрәк сызлый, моңлана?
Күңел кошы аның
Еракларда булса,
Сагына, уйлый икән кыз бала.
Сабырлыгым бетте,
Кавышыр көннәр җитте.
Кайтчы, иркәм, тизрәк
Кайт инде, ай-й, кайт инде...
Кайтам диеп әйттең,
Еракларга киттең.
Салдың мине сагыш утына...

Сөембикә Вәлиева җырыннан.

2 алып баручы. Аллаһы Тәгалә сынауларны яраткан кешесенә җибәрер, диләр халыкта. Әлфияне дә ятимлек ачысы һаман сагалый икән. Закирә апасын бер уч бодай өчен төрмәгә утырталар. Ә Әлфиянең — алда... Әлем. Ә Әлемдә аның кебек ятимнәр тәрбияләнә торган балалар йорты.

Сәхнәгә 13-14 яшьләрдәге Әлфия чыга. Экранга бер-бер артлы Әлфия Афзалова архивыннан алынган фотосурәтләр чыгарыла.

...Актаныш — Әлем арасы —
Тау менәсе-барасы.
Язмышыма язылгандыр
Караның да карасы.
Ат юлы — алты чакырым,
Атлыйм җәяү, ялгызым.
Җәяүләп чыккан буран да
Бара икән, җыр суза!
Ертылып беткән бишмәтнең
Итәгеннән җыр тарта;
Тишек, тузган чабаталар
Үземә җыр тыңлата...

Мөхәммәт *Мирза"Ак пароход" поэмасыннан өзек.*

"Балалар йортында яшәгән чакларымны мәңге онытасым юк. Дәрес әзерләргә утырсак, әле ручкасы, әле дәфтәре җитми иде. Газета-журналларның ак җирләрен файдалана идек. Ә менә сез, балалар, кәгазьләрне кадерләп тотыгыз, дәфтәрләрегезне саклагыз! Әле дә чүп савытында яткан, башланган да ташланган дәфтәрләрне күреп йөрәгем әрни. (Пауза)

Ни дисәң дә, балалар йортында яшәү үзе бер күңелле иде. Җырлый да, бии дә, концертлар да алып бара идем. Шулай Әлемдә 7 сыйныфны тәмамлап, балалар йортыннан чыктым. Чыккач кая барырга? Шул Актаныш инде... Җыракай төрмәдә булгач, күрше Гашия апаларга кайтып егылдым. Өч-дүрт айдан сулыгып, ябыгып Җыракай да кайтып керде...”

Татар халык җыры “Актаныш басмалары”

1 алып баручы. Әлфиянең язмышы аяктан егарлык авыр булса да, юлында яхшы кешеләр күп очрый аның. Нәкъ шул кешеләрнең ятимә кыз язмышындагы рольләре бер генә түгел, берничә кешенең тормышын уңай якка үзгәртеп җибәрергә ярдәм итә. Актаныш район партия комитетының беренче секретаре Сәхаби Камалиев, район культура бүлеге мөдире Кәримә Рәяновалар кызны Актаныш МТСының клубына китапханәче һәм оештыручы итеп эшкә урнаштыралар. Инде Актанышта һәркем таныган Әлфиясез бер генә бәйрәм чарасы үтми. Әйтерсең бәхет кошы үзе килеп керә кызның кулына! Ә фотограф Мәрзия апа Юнысова нинди генә матур, моңлы, кеше күңеленә үтеп керә торган җырлар өйрәтми аңа! “Әллүки”, “Зиләйлүк”, “Уел”, “Гөлҗамал”, “Кәккүк”...

Җыр. “Кәккүк” (аудиоязма тыңлау) (С. Габәши көе)

2 алып баручы. 1950 еллар ахыры. Актаныш район партия комитетының беренче секретаре Сәхаби Камалиев Әлфия Авзалова янына килә дә, болай ди: “Талантыңны әрәм итмә, кызым, Казанга бар, укы!” Шулчак гүя яшүсмер күңелендә, кечкенәдән сер итеп кенә йөрткән, буй җитмәс хыялы дип саналган теләк яшен булып яшьни, гөрләвекләр булып ага, йөрәге, ярларыннан ташып чыгарга әзер булган ярсу елга сыман, шашынып-шашынып тибә башлый. Хәзер ул киләчәген ачык күзаллый. Әйе, ул җырчы булачак, халыкның моңга сусаган җанына саф чык тамчысы булып тамачак!

1 алып баручы. Уйлый-уйлый да Әлфия апа Афзалова, Казанга китәргә карар кыла. Чөнки ул җыр белән яши, җырга табына. Җыр — аның якты маягы, яшәү мәгънәсе! Ә Казан һаман үзенә тарта, сихерли. Бер ятимгә урын табылыр микән соң Казан тиклем Казанда? Ә Актаныш... нәрсәгәдер үпкәләгән бала сыман турсайган, йөзен читкә борган сыман тоела. Тиздән аны ак пароход матур киләчәккә алып китәчәк. Алып китәчәк тә, татар иленә моң алиһәсен бүләк итәчәк...

Сәхнәгә 17 яшьләр чамасындагы буй җиткән Әлфия чыга. Өстендә матур итеп чигелгән ак кофта, бер кулында клеенкадан Закирә апасы тегеп биргән сумка, ә икенчесендә ак кульяулык. Экранда Рабит Батулланың “Моң патшабикәсе фильмыннан өзек дәвам итә. Агыйдел күренеше, ярда ак пароход. Палубага пассажирлар кереп тулган. Озатып калучылар ак кулъяулык болгый.

Әлфия. И Актаныш!.. Җырлы-моңлы Актаныш!.. Хуш! Сау бул!.. Хуш минем нарасый, ятим балачагым!.. Хуш ятим үткән яшүсмер

елларым!.. Хуш, сау булыгыз, дус-ишләрем!.. Хуш, Агыйдел!.. Актанышны назлап тын гына ага бир, гүзәл Агыйдел!.. *(хушлашу сүзләрен әйтеп, ак күлъяулыгын болгый-болгый чыгып китә)*

(Укучылар Мөхәммәт Мирзаның "Ак пароход" поэмасыннан өзекләр укыйлар).

1 укучы.

Ак пароход көтеп алдым,
Бөдрә талга сөялеп.
Юлга алдым җырларымны,
Китим әле төялеп.
Җырга сусаган җаннарның
Сусавын ник басмаска?
Пароход куласасы да:
"Җырла, җырла, — ди ләса.

2 укучы.

— Борыл! — диеп, ач ятимлек
Арттан чаба, чакыра...
Борылмамдыр, җырлар җырым
Казаннарга чакыра!
Борылмамдыр, монда дуслар,
Якыннарым булса да,
Монда елап калса да.

3 укучы.

Җырларымда Актанышка
Мин әйләнеп кайтырмын.
Әргәнештә, алсуланып,
Җыр-таң булып атармын.

4 укучы.

Кузгалаклы балачагым,
Тузганаклы балачак,
Әнкәйләрсез балачагым,
Әкият тулы балачак.
Моң-сагышлы балачагым,
Җырлы-көйле балачак
Елап монда калачак.
Бала җаным, бала акылым —
Гомерлеккә калачагым —
Үзем белән барачак.
Җырларымда яначак!!!
Җырларымда яначак!!!

Җыр. "Хуш авылым" (С. Сәйдәшев көе, Х. Фәтхуллин сүз.)

1 укучы.

Күптән инде, күптән көткән иде,
Чү, офыкта ул ич — ah, таныш;

Ерак юлдан кайткан газиз кызын
Сагынып каршы алыр Актаныш!

Әхмәт Рәшит, *“Нурлы җырлар белән” шигыреннән өзек.*

2 укучы.

Иртә-кич сайрый да сайрый —
Юана татар җаны.
Шулай ярата икән ич
Сандугач кына аны!..
Сайрый күр! Җиде… юк, җитмеш, йөз!
Миллион татар тыңлар!..
Синең җырың җыр гынамы? —
Сандугач сузган моңнар!..

Роберт *Әхмәтҗан.*

Сәхнәдә янәдән Әлфия Афзалова. Экранда — Казан урамнары күренеше.

Әлфия Афзалова. Каршымда — Казан, бөтен татар дөньясының иләһи зур шәмдәле! Тукай, Сәйдәш моңнары дөньяга килгән мәшһүр Казан!.. Мине, татарының бер ятимә кызын үз кочагыңа ал! Олуг шәхесләр иҗаты белән очрашып, аларның җырларын гасырларга калдырыр өчен, милләтемнең асыл җәүһәрләрен халыкка кайтарыр өчен килдем мин сиңа! Саумы, бөек башкалам! Каршы ал мине, Казан!..

Җыр. “Ватанымның гади бер кызы мин” (Г. Зәйнашева сүзләре, А. Ключарев көе)

Кичә тәмам.

Кулланылган әдәбият

1. Афзалова Әлфия. Үзем турында (Җыр, сәхнә — минем тормышым, язмышым). Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. — 189 б.
2. Рабит Батулла. Әлфия Афзалова: истәлекләр, әңгәмәләр, мәкаләләр, фоторәсемнәр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. — 214 б.
3. Актанышым — ак илем/ Төз. И. Хәлиуллин. — Казан: “Идел-пресс”, 2010. — 544 б.
4. Ягъсуф Шәфыйков. Актанышка кайта юлларым. Казан: “Сүз” нәшрияты, 2010. — 244 б.
5. Документаль фильм. Рабит Батулла “ Моң патшабикәсе”, 2010 ел.

Әхтәмова Гөлназ Мингали кызы,
Казан шәһәре Совет районы
175 нче гомуми урта белем мәктәбенең
югары категорияле туган тел һәм әдәбият укытучысы

КОЯШЛЫ ИЛ — БЕЗНЕҢ ИЛ

(ТАССР оешуның 100 еллыгына багышлана. 6 нчы сыйныф)

Метапредмет нәтиҗәләре: эшчәнлекне планлаштыра белү, туган ягыбыз турында булган белемнәрне киңәйтү, эзлекле һәм логик фикер йөртү, мөстәкыйль рәвештә карарлар кабул итә белү, бәйләнешле сөйләм телен үстерү, проект эшчәнлеге тәҗрибәсен яклау.

Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр: туган ягыбызның тарихына, мәдәниятенә карата патриотлык, горурлык хисе, эшчәнлектә бер-береңә карата ихтирам хисе тәрбияләү.

Эшчәнлек юнәлеше: гомумиинтеллектуаль.

Формасы: туган якны өйрәнүчеләр клубы.

Җиһаз: презентация, интерактив такта, документкамера, Татарстанның тарихын, шәһәрләрен, мәдәниятын, сәнгатен, сәнәгатен, күренекле язучы-шагыйрь, галимнәрен яктырткан рәсемнәр стенды, “Татарстан Республикасы тарихы”н яктырткан китаплар күргәзмәсе, төрле төсле карточкалар, сандык, маршрут бите, музыка, проект яклау өчен “Татарстан” темасына конверттагы төрле рәсемнәр, ТАССРның 100 еллыгы логотибы төшкән магнитлар.

Дәрестән тыш чара барышы.

I. Оештыру өлеше.

Укучылар төркемнәрдә укытучыны каршы алалар. Укытучы исәнләшкәннән соң утырышалар.

Укытучы. Исәнмесез, укучылар. Без сезнең белән туган якны өйрәнүчеләр клубына җыелдык. (музыка). Чарабызда без сәяхәткә чыгарбыз. Ой, компьютер хата чыгара. Компьютер эшләп китсен өчен кодлы сүз әйтергә кирәк. Берәрегез белмиме?

Укучылар. Белмибез.

Укытучы. Хикмәт ребуста икән бит. (Слайдта ребус бирелгән.) Әйдәгез, бирелгән ребусны чишик. (Картиналар һәм кушымчаларны берләштерү.)

Укучылар. Кояшлы ил — безнең ил

Укытучы. Димәк, укучылар нәрсә турында сөйләшербез?

Укучылар. Кояшлы илебез турында. Татарстан, Казан турында.

Укытучы. Туган ил сезнең өчен ул нәрсә?

Укучылар. Туган ил ул — минем әти-әнием, дусларым, туганнарым, мәктәбем, шәһәрем, авылым һ.б.

Укытучы. Мин сезне автобуста сәяхәткә чакырам. Мондый ике катлы автобуста сәяхәт иткәнегез булдымы?

Укучылар. Булды./ Булмады.

Укытучы. Бирелгән маршрут буенча без хәрәкәт итәрбез. Иң соңгы тукталышта безне нәрсә көтә?

Укучылар. Сандыктагы хәзинә.

Укытучы. Бу хәзинәне сез табарга әзерме?

Укучылар. Әзер.

Укытучы. Биремнәрне фронталь, парларда да, төркемнәрдә дә эшләрбез. Төркемнәрдә эшләгән вакытта үзара киңәләшеп, ярдәмләшеп дөрес матур җөмләләр белән җавап бирергә тырышырбыз.

– Укучылар, басабыз, автобуска күчеп, урындыктагы яшел төсле карточкаларны алып утырабыз. Әйдәгез, куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәп, ременьнәрне каптырабыз. Киттекме?

Укучылар. (Автобус кузгалып китү тавышы). Киттек.

II. Терәк белемнәрне хәтердә яңарту.

Укытучы. Укучылар, без нинди тукталышка килеп җиттек?

Укучылар. **“Уйла, фикерлә”** тукталышы.

Укытучы. Сезнең алдыгыздагы яшел төсле карточкаларда сораулар бирелгән, әйдәгез, парларда киңәшләшеп җавап бирик. Уң якта утыручылар сорауны укый, сул якта утыручылар җавап бирер.

Укучылар.

1 нче пар сораулары. Татарстан Республикасының башкаласы нинди шәһәр? Татарстанның символларын әйтегез.

2 нче пар сораулары. Татарстанның беренче һәм хәзерге президентын атагыз.

3 нче пар сораулары. Татарстанның иң зур байлыгы нәрсә? Ул кайсы шәһәрдә чыгарыла?

4 нче пар сораулары. КамАЗ машинасы кайсы шәһәрдә җитештерелә?

5 нче пар сораулары. Татарстанда 2019 нчы елның август аенда нинди зур вакыйга булачак?

6 нче пар сораулары. ТАССР 1920 нче елда оешкан. Бу вакыйга үзенең 100 еллыгын кайчан билгеләп үтәчәк?

(Татарстан китап нәшрияты тарафыннан чыккан китапларга нигезләнеп әңгәмә оештыру.)

Укытучы. Афәрин, бик дөрес җавап бирдегез. Юлыбызны дәвам итәбез. (Автобус кузгалып китү тавышы)

III. Яңа мәгълүмат бирү.

Укытучы. Безне нинди тукталыш көтә?

Укучылар. **“Саннар безгә ни сөйли»** тукталышы.

Укытучы. Төз итеп утырабыз. Каешлар турында онытмыйбыз. Әйдәгез, киттек! Бу тукталышта сезгә Татарстан турында җөмләләр бирелгән, ә саннары төшеп калган. Әйдәгез, аларны урыннарына урнаштырабыз. Кул күтәреп җавап бирәбез һәм тиешле урынга күчереп куябыз. (Смарт такта өстендә эш).

Татарстанның мәйданы: 68,0 мең. кв. км

Татарстанда 21 шәһәр, 43 район бар.

Республикабызда 4 зур елга ага: Идел, Кама, Нократ, Агыйдел.

Халык саны: якынча 4 млн кеше.

Республикада 115 милләт вәкиле дус һәм тату булып яши.

Укытучы. Афәрин, булдырдыгыз!

Укытучы. Сәяхәтебезне дәвам итәбез. Автобуска җайлап утырдык, ременьнәрне каптырабыз. Киттекме? (Автобус кузгалып китү тавышы).

— Киләсе тукталыш нинди?

Укучылар. **“Иҗат бакчасында”.**

Укытучы. Бу тукталышта без нишләрбез?

Укучылар. Иҗат итәрбез.

Укытучы. Әйе, укучылар, “Иҗат бакчасында” без шигырь язып карарбыз. Менә тукталышка килеп тә җиткәнбез. Басабыз. Урыннарга утырабыз. **Сары төсле** карточкаларны алабыз. Бу биремне төркемнәрдә үзара киңәшләшеп, бирелгән шигырьнең дәвамын язып бетерәбез. Башладык.

Укучылар. 1 нче төркем җаваплары.

Туган ил ул — әти-әнием,

Туган ил ул — минем гаиләм.

Туган ил ул — минем мәктәбем,

Туган ил ул — якын дусларым.

Укучылар. 2 нче төркем җаваплары.

Туган ил ул — шәһәр, авыллар,

Туган ил ул — елга, урманнар.

Туган ил ул — якын туганнар,

Туган ил ул — туган нигезләр.

Укытучы. Төгәлләдек. Беренче төркем, әйдәгез әле, шигырегезне укып бирегез.

— Афәрин! Икенче төркем, әйдәгез, сезне тыңлыйбыз.

— Әйе, укучылар туган илебез ул әти-әниләр дә, туганнар да, дуслар да, мәктәбебез дә, урамыбыз да.

— Булдыргансыз!

— Ә хәзер бирем. Бу шигырьләрне төркемнәрдә шатлык һәм горурлык интонациясе белән укып күрсәтегез әле.

Укучылар. Әйдәгез!

Укытучы. Афәрин. Әйдәгез, шигырьләрне рәп итеп җырлап карыйк.

Укучылар. (Җырлыйлар.)

Укытучы. Кул чабыйк әле, ничек матур җырладыгыз!

IV. Белемнәрне билгеле бер системага салу, гомумиләштерү.

Юлыбызны дәвам итәбез. Киләсе тукталыш — **“Кунакка рәхим итегез”.** Күз алдына китерегез: сез экскурсоводлар. Кунакка килгән туристларны Татарстан белән таныштырасыз. Моның өчен конвертта

бирелгән рәсемнәрне кулланып, проект эше эшләрбез. Өстәлдә яткан конвертларны алдык. Сез кунакларны ТАССРның 100 еллыгына кунакка чакырырсыз. Стенд рәсемнәренә дә игътибар итегез. Тукталышларда алган белемнәрне дә кулланып, эшегезне киңәшләшеп башкарырсыз. 2-3 укучы проектыгызны тәкъдим итәр. Башладык. (Документкамера аркылы проектны карау һәм яклау. ТАССР оешуның 100 еллыгын азсызыклап китү.)

Укытучы. Сездән чын экскурсоводлар чыга икән бит. Кул чабып алыйк әле. Әйтегез әле, һәрбер турист истәлеккә нәрсәләр алып китәргә мөмкин.

Укучылар. Сувенирлар, һ.б истәлекле бүләкләр.

Укытучы. Менә сандыкны ачар вакыт җитте. Монда нәрсә яшеренде икән?

Укучылар. Сувенирлар — мангит, значок, чынаяк, блокнот һ.б.

Укытучы. Әйдәгез, карыйбыз. Бу кечкенә генә бүләкләр бүгенге чарабызның истәлеге булып калыр дигән теләктә калам. (ТАССРның 100 еллыгы логотибы төшкән магникларны тарату.)

V. Рефлексия. Укытучы. Тактада өч дәрәҗәле баскыч бирелгән. Бүгенге чарада алган белемнәргә таянып, сез Татарстан турында кайларда чыгыш ясый алыр идегез?

1. Сыйныф.

2. Мәктәп күләмендә.

3. Район, шәһәр, республика күләмендә.

Укытучы. Укучылар, мин сезнең актив булуыгызга бик шат. Үз-үзегезгә ышанычыгызны беркайчан да югалтмагыз. Һәрвакыт шундый актив, ачык булыгыз дигән теләктә калам.

Җаваплары гыз өчен сезгә бик зур рәхмәт.

Шуның белән чарабыз тәмам. Сау булыгыз.

Кушымта 3

Туган тел (татар теле) һәм әдәбият буенча тәкъдим ителә торган проект эше темалары

1) Әбием сандыгы.
2) Бәетләр иленде. Авылымның оста бәетчеләре.
3) Бүгенге көн яшүсмерләренең теле. Лингвистик экспертиза.
4) Бүгенге татар эстрада җырлары. Лингвистик экспертиза.
5) Г. Тукай (бүтән әдипләр) әсәрләрендә экология (музыка сәнгате, сәясәт, туган илгә (туган телгә, әти-әнигә, хатын-кызга, хезмәткә, һ.б.) мәхәббәт) мәсьәләләре.
6) Газеталарда сүз куллану үзенчәлеге.
7) Гаиләбез йолалары.
8) Гаиләдә һөнәр ияләре.
9) Грамматик кагыйдәләрне өйрәнү кирәкме?
10) Грамоталы булу — заманча булу?
11) Диалог төзү осталыгы.
12) Ел фасыллары (“Кышкы бизәкләр”, “Яз”, “Ямьле җәй”, “Алтын көз”) (сүзлекчә, шигырьләр һәм иншалар җыентыклары, презентацияләр, видео).
13) Икетеллелек һәм сөйләм культурасы.
14) Исем (фигыль, аваз ияртемнәре, һ.б.) темасын өйрәнү тормышта кирәкме?
15) Казан Кремле. Дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музеена сәяхәт. (презентация)
16) Каләм изгегә тартыр (якташ әдипләр иҗатына багышлап).
17) Кем мин — татар булмасам?
18) Кибеттә сөйләшү. Видеоролик.
19) Китапка ничә яшь?
20) Күп телләрне белү — яхшы шөгыль, туган телең үги калмаса.
21) Кыскалыкта — осталык: реклама теле.
22) Кыскартылма сүзләр. Лингвистик экспертиза.
23) Лингвистик география. Җирдә ничә тел бар?
24) Матур сүзләр сандыгы.
25) Мәгълүмат чараларының сөйләм теленә тәэсире.
26) Мәкаль һәм әйтемнәрдә ялгызлык исемнәре.
27) Мәктәбем тарихы.
28) Мәктәп музее — илһам чыганагы.
29) Минем яраткан кинофильмнар.
30) Мультфильмнар иленде (мультфильмнарны тавышландыру).
31) Һөнәр үзләштерәбез.
32) Районыбызның күренекле шәхесләре сериясе.
33) Рус һәм татар теле җөмләләренең кайбер үзенчәлекләре.
34) Рус һәм татар теле сүзләренең үзара семантик бәйләнеше.
35) Рус һәм татар телендәге исемнәрнең үзара мөнәсәбәте.
36) Рус һәм татар фразеологизмнарының нисбәте.
37) Сәхнә әсәрләре теле. Лингвистик экспертиза.
38) Сөйләм культурасын формалаштыруда фразеологизмнарның роле.

39) Сөйләмдә кисәкчәләрне дөрес куллану.
40) Сулыкларда Су анасы елый.
41) Сүз ясалышының кызыклы очраклары.
42) Сыйфат иленә сәяхәт.
43) Сынамышларда һава торышы.
44) Табышмаклар илендә.
45) Табышмакларда сыйфатлар.
46) ТАССР оешуга 100 ел. Сценарий.
47) Татар җырларында стилистик хаталар.
48) Татар алфавиты тарихы. Презентация.
49) Татар әлифбасы тарихы. Презентация.
50) Татар китапларының килеп чыгышы.
51) Татар һәм рус телендә килешләрнең уртак һәм аермалы яклары.
52) Татар теле кагыйдәләре альбомы.
53) Татар телен өйрәтү кушымтасы.
54) Татар телендә астрономик атамалар.
55) Татар телендә басым куелу үзенчәлекләре.
56) Татар телендә рус сүзләренең урынсыз кулланылу очраклары.
57) Татар теле лексикасының баю юллары.
58) Татар теленең хәзерге неологизмнары. Интернет сәхифәләренә лингвистик анализ.
59) Татар теленең хәзерге сленгы. Лингвистик анализ.
60) Татар халкының кием-салым атамалары.
61) Татар халкының милли бәйрәмнәре һәм йолалары.
62) Татар халык әкиятләрендә ай.
63) Татар халык әкиятләрендә миллилек.
64) Татар халык әкиятләрендә сурәтләү чаралары.
65) Татар халык әкиятләрендә явызлык һәм мәрхәмәтлелек.
66) Татар халык мәкальләрендә ана темасы.
67) Татар халык мәкальләрендә гаилә темасы.
68) Татар халык мәкальләрендә сурәтләү чаралары.
69) Татар халык мәкальләрендә туган ил, Ватан темасы.
70) Татар халык һәм рус халык әкиятләрендә песи образы.
71) Татар халык сынамышларында төш.
72) Татар халык уен кораллары.
73) Татар халык уеннары.
74) Татар халык юраулары.
75) Татар этнонимының этимологиясе.
76) Татар язуы тарихыннан.
77) Татарча-кытайча сүзлекчә. Төп 50 сүз.
78) Татарча-русча алтакта исемнәрен күзәтү.
79) Татарча-японча сөйләшмәлек. 50 төп фраза.
80) Телебездә алынма сүзләр. Алар телне баетамы, әллә бозамы?
81) Туган телем — горурлыгым (21 февраль — Туган тел көненә багышлап).
82) Туган телем — татар теле (иншалар җыентыгы).
83) Туган ягыбыз томонимнарының этимологиясе.
84) Туган ягым — гөлләр иле (Авылымның истәлекле урыннарын өйрәнү).
85) Тукай әкиятләре татарча мультфильмнарда (“Татармультфильм” сайтыннан файдаланып).

86) Тылсымлы сүзләр.
87) Тыныш билгеләре ни өчен кирәк?
88) Халык сынамышлары теле.
89) Хикмәтле дә, бизәкле дә туган тел (якташ шагыйрьләребез иҗатына күзәтү).
90) "Шаян-ТВ" — яраткан телевизион каналым.
91) Шәһәребез урамнарында татар сүзләре ничек язылган?
92) Шәһәребездәге кибет исемнәрендә ономастика.
93) Шәүкәт Галиев шигырләрендә ялгызлык исемнәр.
94) Шәхес — халык тарихының, милләтнең бер кисәге (Авылымның күренекле кешеләренә багышлап).
95) Шүрәле — урман сакчысы.
96) Эндәш сүзләр (сүзлекчә).
97) Эш кәгазьләрен татарча язу. Лингвистик экспертиза.
98) Яңа һөнәрләр һәм аларның аталышы.
99) Яшьләр нинди темага китаплар укый?
100) Яшьләр арасында татар теленең кулланылыш даирәсе.

ЭЧТӘЛЕК


Гомуми белем бирү оешмаларында дәрестән тыш эшчәнлекне оештыру үзенчәлекләре 3
Дәрестән тыш эшчәнлекне оештыруда төп принциплар һәм модельләр 5
Белем бирү процессының гамәли-эшчәнлекле нигезе. Дәрестән тыш эшчәнлек нәтиҗәләре 7
Дәрестән тыш эшчәнлек аша туган телне (татар телен) һәм әдәбиятны укытуны ныгыту мөмкинлекләре 11
Әдәбият исемлеге 14
Кушымта 1 16
Кушымта 2 21
Кушымта 3 37

ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕН)
ҺӘМ ӘДӘБИЯТНЫ УКЫТУДА
ДӘРЕСТӘН ТЫШ ЭШЧӘНЛЕКНЕҢ РОЛЕ

Форм.бум.60х84 1/16. Усл.п.л. 2,4
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ
420015 Казан, Зур Кызыл ур., 68
Тел.: (843)236-65-63 тел./факс (843)236-62-42 E-mail: irort2011@gmail.com

ПАРТНЕРЫ ИНСТИТУТА



























































Уважаемые коллеги, приглашаем к сотрудничеству!

СОВРЕМЕННОЕ ОБРАЗОВАНИЕ: АКТУАЛЬНЫЕ ВОПРОСЫ И ИННОВАЦИИ

Свидетельство о регистрации СМИ: ЭЛ № ФС 77-74813

(выдано Федеральной службой по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций)



Территория распространения:
Российская Федерация и зарубежные страны
Периодичность: четыре раза в год
Опубликованные материалы будут размещены в Научной электронной библиотеке (**e-library.ru**) и войдут в базу данных **Российского индекса научного цитирования (РИНЦ)**
Контактное лицо: Шайхутдинова Галия Айратовна
Адрес электронной почты: smi@irort.ru

Подробная информация для авторов http://irortsmi.ru/node/3

АКТУАЛЬНАЯ ПЕДАГОГИКА



Территория распространения:
Российская Федерация и зарубежные страны
Свидетельство о регистрации: ПИ №ФС77-75641 от 26 апреля 2019 г.
Материалы публикуются на русском и татарском языках
Контактное лицо: Абдулаев Валерий Анатольевич
Номер телефона редакции: 8 937610 37 60
Адрес электронной почты: vabdulaev@inbox.ru







Институт развития образования
Республики Татарстан
420015, Казань, Большая Красная, 68
(843) 236-65-63, 236-62-42
irort2011@gmail.com